**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 29 октябрендәге 4561 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 11 ноябрендәге 4609 номерлы «Казан шәһәрендә ябык типтагы түләүле муниципаль парковкалар булдыру турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында

Казан шәһәре территориясендә бердәм парковка мәйданы эшен тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законнарга һәм 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы законына таянып, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 18 апрелендәге 2096 номерлы «Казан шәһәрендә парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм алардан, шул исәптән түләүле нигездә, файдалану тәртибе турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм:**

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 11 ноябрендәге 4609 номерлы «Казан шәһәрендә ябык типтагы түләүле муниципаль парковкалар булдыру турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 29 сентябрендәге 3329 номерлы, 2024 елның 28 августындагы 3618 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтасын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карар кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 11 ноябрендәге 4609 номерлы карарына кушымта дип санарга;

1.3. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) юл хәрәкәтен оештыруда үзгәреш турында массакүләм мәгълүмат чаралары, социаль медиаресурслар аша юл хәрәкәтендә катнашучыларга хәбәр итәргә **тәкъдим итәм.**

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим.**

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 29 октябрендәге
4561 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәрендә ябык типтагы**
**түләүле муниципаль парковкалар реестры**

| № т/б | Исеме, адресы | Машина урыннары саны | Парковка урыннарыннан файдаланган өчен түләү күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | «Авиатөзелеш» метро станциясендә җир асты парковкасы | 189 | 1 сәгатькә кадәр – 50 сум;<br>1 сәгатьтән 3 сәгатькә кадәр – 75 сум;<br>3 сәгатьтән 10 сәгатькә кадәр – 150 сум;<br>10 сәгатьтән 14 сәгатькә кадәр – 200 сум;<br>14 сәгатьтән артык – тәүлеккә 250 сум;<br>24 сәгатьтән артык булганда исәп-хисап вакыты бер тәүлеккә кадәр түгәрәкләнә;<br>18.00 сәгатьтән 08.00 сәгатькә кадәр (төнге тариф) – 120 сум;<br>бер айга абонемент – 4500 сум;<br>бер кварталга абонемент – 12000 сум;<br>12 айга абонемент – 42000 сум |

_______________